ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур, 1 А

СОВЕТ АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Айбаш , ул. Центральная, д. 1 А

тел./факс 8(84365) 6-07-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** | **РЕШЕНИЕ**

**9 сентябрь 2020 ел** | **№ 192**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Айбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 166 номерлы карары (2019 елның 20 декабрендәге 174 номерлы редакциясендә) белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә, Айбаш авыл җирлеге Уставына таянып, Айбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирләүгә тарифлар билгеләү һәм җирләү эше өлкәсендә җирле үзидарә вәкаләтле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга;
2. Әлеге карарны карау өчен Биектау муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә (Сафиуллин Равил Рәкыйп улы) Биектау муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмаган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзү буенча як булырга;
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сафиуллин